КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 21 июнь г.Казань № 505

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында 2018 ел, 14 август, 665 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте оешмалары һәм Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре буенча министрлыгы ведомствосында булган аерым типик булмаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында 2018 ел, 14 август, 665 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте оешмалары һәм Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре буенча министрлыгы ведомствосында булган аерым типик булмаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары хакындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

V бүлектә:

2.4 пунктның алтынчы абзацында «26,5» саннарын «41,0» саннарына алмаштырырга;

6 таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 таблица

Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмәләр күләме

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | – | 41,0 |
| Икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | беренче | 41,0 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | беренче – дүртенче | 41,0 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | беренче | 46,0 |
| | икенче | 49,0»; |

4.4 пунктның алтынчы абзацында «26,5» саннарын «41,0» саннарына алмаштырырга;

11 таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 таблица

Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмәләр күләме

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Вазыйфа исеме | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| «Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | барлык вазыйфалар | 41,0 |
| «Урта буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | аккомпаниатор, костюмнар бүлмәсе мөдире | 49,0 |
| | түгәрәк, һәвәскәр берләшмә, мәнфәгатьләр клубы җитәкчесе, мәдәни оештыручы | 61,0 |
| «Әйдәүче буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | барлык вазыйфалар | 49,0 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | барлык вазыйфалар | 49,0»; |

VIII бүлекнең 8 пунктындагы бишенче абзацта «10» саннарын «20» саннарына алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин